РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
**Осинниковского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Молодежная, д.9А п.Осинники, 422824
тел. (884377) 33929 факс: (884377) 33929
e-mail:adm@kama-tamagy.gov.tatarstan.ru
ОКПО 42150535 ОГРН 1031638400419
ИНН/КПП 1622001890/162201001

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Осинники авыл жирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Молодежная урамы, Д. 9А п.Осинники, 422824,
тел. (884377) 33929 факс: (884377) 33929
e-mail:adm@kama-tamagy.gov.tatarstan.ru
ОКПО 42150535 ОГРН 1031638400419
ИНН/КПП 1622001890/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 22 октябре №1

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлегенең Осинники торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге Уставының _ ст. нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлегенең Осинники торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 10 ноябрендә 11.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, күпбалалы гаиләләр биш һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары, көндезге формада белем алучы студентлар) 2021 елда 300 сум күләмендә салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән сез ризамы:

- вак таш җәелгән юлны ремонтлау;
- зират коймасын ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Осинники п., Яшьләр ур., 9А йорт (административ бина);
- Осинники п., Лесная ур., 2 йорт (Осинниковский СДК),

шулай ук кабул ителгән көннән алып 5 (биш) көн эчендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән (басылып чыккан) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Осинники
авыл җирлеге башлыгы А.Х.Сәгъдиев